## “Тел – күңел көзгесе” районара конференциясенең НИГЕЗЛӘМӘСЕ

### I. Гомуми нигезләмә

Әлеге нигезләмә “Тел – күңел көзгесе” районара фәнни-гамәли конференциясен үткәрү тәртибен билгели. Конференция читтән торып (заочно) оештырыла.

### II. Конференциянең максат һәм бурычлары

2.1. Конференциянең максаты – филологик, тәрбия юнәлешендәге, эзләнү эшчәнлеге аша укучыларның иҗади фикер йөртүләрен, сәнгатьле сөйләм сәләтләрен, укытучыларның профессиональ осталыкларын арттыру.

2.2. Конференциянең бурычлары:

хәзерге заман укучысының гомуми һәм коммуникатив культура дәрәҗәсен, социаль активлыгын үстерү һәм җәмгыятьтә үз урынын табарга өйрәтү;

талантлы балаларны барлау, алга таба аларның сәләтләрен үстерүгә мөмкинлекләр тудыру, ярдәм итү;

укучыларның һәм укытучыларның иң яхшы казанышларын, белем бирү оешмаларының фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнү тәҗрибәсен өйрәнү, тәкъдим итү һәм пропагандалау;

эшне тәкъдим итүче коллективлар белән иҗади бәйләнешләр формалаштыру, үзара аралашу оештыру;

укытучыларның профессиональ осталыкларын үстерү, камилләштерүгә этәргеч ясау.

### III. Конференцияне оештыручылар

Конференцияне оештыручылар:
Сарман муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге,
Сарман районы МБГББУ “Сарман гимназиясе”

### IV. Бәйгедә катнашучылар

4.1. Конференциядә катнашу өчен мәктәп, гимназия, лицейларның 1 – 11 нче сыйныф укучылары һәм туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучылары, сыйныф җитәкчеләре чакырыла.

### V. Конференциянең эш юнәлешләре

Конференция түбәндәге юнәлешләр буенча оештырыла:

- Тел турында авторлык шигырь бәйгесе (5-7 нче сыйныф укучылары өчен, ворд программасында язып беркетелә)
- Сәнгатьле сөйләм бәйгесе ( 8-9 нчы сыйныф укучылары өчен, видеоязма рәвешендә)
- Татар җыры бәйгесе (1-11 нче сыйныф укучылары өчен, видеоязма рәвешендә)
- Авторлык программалары бәйгесе (укытучыларның татар теле, татар әдәбияты, тәрбия юнәлешендәге эшләре кабул ителә)

## VI. Фәнни-гамәли эшләргә таләпләр

6.1. Эшләр кабул ителгән стандарт кысаларында билгеле бер тәртипкә нигезләнеп языла. Шрифт Times New Roman – 14. Полялар: сулдан – 30 мм, уңнан – 15 мм, астан һәм өстән – 20 мм. Юл араларында 1,5 интервал кала. Кызыл юл 1см калдырып башлана. Видеофайллар MP4 форматында беркетелә.

Конференциягә башка конкурсларда, конференцияләрдә катнашып, призлы урын алган, матбугатта басылган эшләр кабул ителми.

## VII. Бәйгене үткәрү һәм катнашу тәртибе

7.1. Заявка, фәнни-эзләнү эшләре **2023 нче елның** 20 **нче февраленә кадәр,** авторның фамилиясе күрсәтелеп, konferencia-sarman@yandex.ru электрон адресына җибәрелә. Белешмәләр өчен телефон: 89600756175 (сорауларыгыз булса, ватсапка язуыгызны сорыйбыз, шалтыратулар кабул ителми)

7.2. Конференция **читтән торып** үтә. 2023 нче елның 20 нче февраленә кадәр килгән эшләр тикшерелә. Килгән эшләрне, оештыру комитеты составына кергән экспертлар тикшергәннән соң, 28 нче февральгә нәтиҗәләр гимназиянең рәсми сайтына куела.

7.3. Конференциядә катнашу өчен заявка түбәндәге формада җибәрелә:

(Заявка формасын үзгәртмәвегезне сорыйбыз!!!)

**Заявка язу конференциядә катнашуга һәм шәхси мәгълүматны урнаштыруга ризалык бирү дип санала.**

| Укучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | Республика, шәһәр (район), мәктәп исеме (устав буенча), | Телефон (мәктәп, укучының кәрәзле | Укучының адресы, индексы | Фәнни җитәкченең фамилиясе, исеме, |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | сыйныфы | телефон номеры) | | этисенең исеме, вазифасы |
| | | | | |

**VIII. Конференцияне йомгаклау һәм нәтиҗә ясау**

8.1. Жюри составына татар телен яхшы белгән, мәгариф һәм мәдәният өлкәсе белән якыннан таныш компетентлы белгечләр кертелә.

8.2. Жюри әгъзасының хокуклары:

Укучыларның һәм укытучыларның эшләренә экспертлар комиссиясе (жюри) бәяләү критерийларыннан чыгып бәя бирә;

карар беркетмәгә теркәлә, үзгәрешсез кабул ителә.

Катнашкан барлык укучыларга һәм укытучыларга мәгариф бүлегенең шаһәдәтнамәсе тапшырыла;

җиңүчеләр һәм призлы урыннарга ия булучылар мәгариф бүлегенең дипломнары белән бүләкләнә.